| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 8 КАРАР

7 ноябрь 2024 ел

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылында 2025 елга үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» карарына узгэрешлэр керту турында

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылында 2025 елга үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» карарына тубэндэге узгэрешлэрне кертергэ:

1.Карарның 2 пункты: Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм армия сафларында хезмәт итучеләрдән тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертүгә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?

**үзгәртергә:**

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм армия сафларында хезмәт итучеләрдән тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертүгә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?

2. 2 пунктта 4 подпункт. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу;)?"; **карардан чыгарырга**.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Сөлек авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы башлыгы Н.Н.Хуҗина